**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Уразаевского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Н.Бадертдинова , д. 35, село Уразаево,
Азнакаевского муниципального района РТ
423303

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авылы жирлеге**
**башлыгы**

Н.Бадертдинов урамы, 35,Уразай авылы
Азнакай муниципаль районы ТР
423303

Тел./факс(885592)43-5-55; E-mail:Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
18 ноябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенец Уразай торак пунктында, Уразай авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024 елның 27 ноябрендэ 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләр һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнар тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 торкем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлту белән килешәсезме:
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән

башка җайланмаларны ремонтлау; Уразай авылындагы урамнарны яктырту җайланмаларын төзеклэндеру;

- Уразай авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлын ремонтлау);

- Уразай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп-чар җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту);

-Уразай авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа, янгын җиһазларе сатып алу).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Уразай авылы, Н.Бадертдинов ур., 35 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: А.М.Шарифуллина